# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **08.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыҮчәлле авыл җирлеге составына керүче, Үчәлле авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Үчәлле авылындагы Совет, Октябрь, Тукай урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен тракторист белән техника арендалау;
- Үчәлле авылы территориясен куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү;
Үчәлле авылында юлларны кардан чистарту;
- Үчәлле авылында җәйге вакытта территорияне чабу;
- Үчәлле авылында («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел») бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;
- Үчәлле авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- җирлек территориясендә үләнне чабу өчен триммерлар, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Үчәлле авылы торак йортлары өчен ике телдә урам күрсәткечләре һәм номерларны сатып алу (әзерләү);
- Үчәлле авылында сугышта һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау (койма урнаштыру, ветераннар исемлеген яңарту, килешү буенча буяу, эшләр өчен түләү) һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары стендын бизәү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина